Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге составына керүче Ташлык авылы

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020 елның 12 декабере № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлегенең Ташлык авылы гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Шәңгәлче авыл җирлеге Шәңгәлче авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертергә. Әлеге сумманың 50% ы күләмендә 2 төркем инвалидлар түли.

- 2. Алынган акчаларны Ташлык зиратын койма белән тотып алу юнәлтергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Шәнгәлче авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Сәлимов